ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 февраль, 2020 ел № 36/6

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыру турындагы Нигезнамәне раслау хакында» 2006 елның 19 октябрендәге 15/8 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 25.10.2006 ел 203-204 саннарында басылган;

2) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыру турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 18/21 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 04.05.2012 ел 34 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 23.05.2012 ел 39 санында басылган;

3) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә табигать саклау билгеләнешендәге җирләрдә хуҗалык эшчәнлеген чикләү турындагы Нигезнамә хакында» 2006 елның 9 июнендәге 13/8 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 24.06.2006 ел 115-117 саннарында басылган;

4) Шәһәр Советының «Казан районара табигать саклау прокурорының 2007 елның 15 февралендәге протесты турында» 2007 елның 4 апрелендәге 21/11 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 18.04.2007 ел 70-71 саннарында басылган;

5) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган территорияләрдән файдалану һәм аларны саклау тәртибе турында Нигезнамә хакында» 2006 елның 9 июнендәге 13/10 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 17.06.2006 ел 110-112 саннарында басылган

6) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының 2006 елның 9 июнендәге 13/10 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм саклау тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 28 декабрендәге 5/5 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 20.01.2016 ел, 3 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 22.01.2016 ел 4 санында басылган.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев